**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Чубар-Абдулловского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Советская, д. 81 , село Чубар-Абдуллово
Азнакаевского муниципального района, 423323
Тел. (факс) (85592)38-7-37
Chabd.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы
Азнакай муниципаль районы, 4233237
Тел. (факс) (85592) 38-7-37
Chab.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**21 октябрь 2025 ел** **№3**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең Буралы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларынкертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы торак пунктында 2025 елның 31 октябрендә 11 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын уздыру вакыты-2025 елның 31 октябрендә 11.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенын үткәрү урыны- Буралы авылы, Октябрьская урамы, 34 нче йорт, Чубар-Абдул авылы мәдәният Йорты залы;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 21 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын

гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Чубар-Абдул авылы, Совет урамы, 81 йорты;

- сайлау хокукына ия булган Буралы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
-Буралы торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2026 елда Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,
- 1 төркем инвалидларыннан,
- көндезге уку формасында укучы студентлардан,
- махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Буралы авылы зиратын киртәләү өчен материал сатып алу)
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Җәлил ур., Октябрь ур., Пионер ур., Мәктәп ур. буенча грейдер белән юлларны тигезләү)
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Буралы авылы юлларын һәм территорияләрен кардан чистарту)

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Буралы авылы, Октябрь ур., 34 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
5. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: Н. Ә. Фәтхетдинов